**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 19 июнендәге 2099 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2020 елның 27 апрелендәге 1282 номерлы**
**«Казан шәһәренең муниципаль предприятиеләре һәм**
**учреждениеләре хезмәтләренә, эшләренә тарифлар турында»гы**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре Думасының 2006 елның 20 апрелендәге 9-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль предприятиеләре һәм учреждениеләре эшләренә һәм хезмәтләренә тарифлар билгеләү тәртибен гамәлдәге законнар таләпләренә туры китерү, шулай ук Казан шәһәре муниципаль унитар предприятиеләре исемлеген актуальләштерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 27 апрелендәге 1282 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль предприятиеләре һәм учреждениеләре хезмәтләренә, эшләренә тарифлар турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4. Казан шәһәре Башкарма комитетының муниципаль предприятиеләрнең хезмәтләренә, эшләренә тарифларны җайга салу буенча вәкаләтле органнары итеп Казан шәһәре Башкарма комитетының түбәндәге органнарын билгеләргә:

- «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе – Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты;

- «Киров районының юл төзекләндерү-эксплуатацияләү идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе, «Горводзеленхоз» тресты муниципаль унитар предприятиесе, «Шәһәр күперләре» муниципаль унитар предприятиесе, «Шәһәрне төзекләндерү» муниципаль унитар предприятиесе – Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты;

- «2 номерлы пассажир автотранспорты предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесе, «Метроэлектротранс» муниципаль унитар предприятиесе – Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитеты»;

1.2. 5.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«5.2. муниципаль учреждениеләрнең төп эшчәнлеккә өстәмә рәвештә күрсәтелә торган түләүле хезмәтләре өчен тарифлар җайга салучы орган тарафыннан раслана»;

1.3. 5.3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«5.3. эшләр башкаруга һәм (яки) хезмәтләр күрсәтүгә контрактларның башлангыч (максималь) бәяләрен, бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән төзелә торган контрактлар бәяләрен, шулай ук эш һәм (яисә) хезмәт күрсәтү берәмлекләренең башлангыч бәяләрен, күрсәтелгән берәмлекләр бәяләренең башлангыч суммаларын һәм контрактлар бәяләренең максималь күрсәткечләрен (башкарылырга тиешле эшләр, күрсәтелергә тиешле хезмәтләр күләмен билгеләү мөмкин булмаган очракта) билгеләү өчен кулланыла торган бәяләр (тарифлар) Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән раслана».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**